РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

09.08.2025 Буа шәһәре № 1-83

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Түбән Нартабаш авыл җирлеге Советының 2013 елның 06 маендагы 4-45 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы «Түбән Нартабаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» карарын гамәлдән чыгару хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законга, «Шәһәр төзелеше эшчәнлегендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы һәм Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Түбән Нартабаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2025 елның 29 июлендәге 1125/о номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Түбән Нартабаш авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Түбән Нартабаш авыл җирлеге Советының 2013 елның 06 маендагы 4-45 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы «Түбән Нартабаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» карарын гамәлдән чыгарырга.
2. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http:pravo.tatarstan.ru адресы буенча басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында https://buinsk.tatarstan.ru. адресы буенча халыкка игълан ителергә тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Буа муниципаль районы башлыгы урынбасары И.Ф. Еремеевка йөкләргә.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Совет Рәисе Р.Р.Камартдинов